ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» мая 2021 ел № 141

ВЗ ВОЛС ОК744 Менделеевск – Әгерҗе территориясе – саклау зонасында территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны билгеләү һәм файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләренең урнашу урынын тасвирлау турында

ПАО «Таттелеком»ның (ИНН 166000732239, ОГРН 1031630213120) 2020 елдның 29 декабрендәге 6432-10/КУЭС – ТТК-ИсхП номерлы территориядән файдалануның махсус шартлары булган чикләр урынының тасвирламасын раслау турында мөрәҗәгатен карап, Россия Федерациясе Җир кодексының 56, 106 статьялары, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Элемтә турында» 2003 елның 7 июлендәге 126-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 33 статьясы, «Россия Федерациясе элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 9 июнендәге 578 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының «Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар турында дәүләт күчемсез милек кадастрына белешмәләр кертү турында» 17.12.2009 № 22066-ИМ/Д23 хатын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны һәм территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләренең урнашу урынын тасвирламасын билгеләргә:

ВЗ ВОЛС ОК744 Менделеевск – Әгерҗе саклау зонасы, гомуми мәйданы 10 992,5 кв. метр, урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы.

2. «Россия Федерациясе элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 9 июнендәге 578 номерлы карары белән каралган территориядән (саклау зонасыннан) файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә тулысынча яисә өлешчә урнашкан җир кишәрлекләренә чикләүләр салырга.

3. ПАО «Таттелеком»га (ИНН 166000732239, ОГРН 1031630213120):

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең күчемсез мөлкәт дәүләт кадастрына территориядән файдаланунын махсус шартлары булган зона турында белешмәләр кертүне тәэмин итәргә;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә муниципаль берәмлекнең милек хокукын дәүләт кадастр исәбенә алу һәм дәүләт теркәве турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә;

әлеге карарда күрсәтелгән гамәлләрне башкарганда, ПАО «Таттелеком» (ИНН 166000732239, ОГРН 1031630213120) ышанычнамәсез эш итәргә хокуклы.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**